МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.05.2015 ел № 205-пр

Казан ш.

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында коррупция куркынычына бәйле булган, дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы структурасы үзгәрүгә бәйле рәвештә һәм “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законны, “Коррупциягә каршы көрәш турында” Федераль законның аерым нигезләмәләрен тормышка ашыру чараларын хакында 30 сентябрь, 2010 ел, № УФ-636 Татарстан Республикасы

Президенты Указын, “Татарстан Республикасы гражданнары дәүләти гражданлык вазыйфасына билгеләнгәндә һәм Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең вазыйфасын биләгәндә керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 30.12.2009 ел, №УП-701 Татарстан Республикасы Президенты Указын, “Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыру хакында” 30 декабрь, 2009 ел, № УП-702 Татарстан Республикасы Президенты Указын үтәү йөзеннән, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) коррупция куркынычына бәйле булган, дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте

вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Вазыйфалар исемлегенә түбәндәгеләрне күздә тоткан вазыйфаи бурычларны үтәүнең кертелүен билгеләргә:

даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләре нигезендә хакимият вәкиле яки оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык функцияләрен үтәү;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

контрольлек чаралары үткәрү;

дәүләт милке белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын хәл итү;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

3. Министрлыкта вазыйфалар исемлегенә кертелгән вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләренә “Коррупциягә каршы көрәш турында” 25 декабрь, 2008 ел, № 273-ФЗ Федераль законның 12 статьясы нигезендә аңлатырга:

дәүләт хезмәте вазыйфасын биләгән, Исемлеккә кертелгән гражданин дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында хезмәт килешүе шартларында вазыйфалар биләүгә һәм (яки) бу оешмада гражданлык (хокукый) килешүе (гражданлык-хокукый килешүләр) шартларында йөз мең сумнан артыграк бәягә бер ай эчендә эшләр башкаруга (бу оешмага хезмәтләр күрсәтүгә) хокуклы, бу оешма белән дәүләти идарә итүнең аерым функцияләре Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи (хезмәт) бурычларына кергән очракта, Министрлыкның дәүләти

гражданлык хезмәткәрләренең хезмәт урынындагы тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу  буенча комиссиясе ризалыгы белән;

Вазыйфалар исемлегенә кертелеп, Министрлыкта дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфасын биләгән гражданин дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң ике ел дәвамында хезмәт килешүләрен яки бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтү) гражданлык-хокукый килешүләре төзегәндә эш бирүчегә соңгы эш урыны турында мәгълүматлар тапшыруга бурычлы;

Вазыйфалар исемлегенә кертелеп, Министрлыкта дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләгән гражданинның дәүләт хезмәтеннән киткәннән соң бу боерыкның өченче абзацында күздә тотылган таләпләрне үтәмәве әлеге гражданин белән төзелгән хезмәт килешүләрен яки бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән эшләр башкаруга (хезмәтләр күрсәтү) гражданлык-хокукый килешүләрен туктатуга китерә.

4. Кадрлар бүлегенә (Р.М.Газизов) бу боерыкны Министрлыкта Вазыйфалар исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәткәрләре игътибарына җиткерергә.

5. “Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары һәм үзләренең ире (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турындагы мәгълүматлар, шулай ук  дәүләти гражданлык

хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында” 22.09.2014 ел, № 477-пр Министрлык Боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Министр** **А.К.Хамаев**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 05.052015 ел, № 204-пр боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында коррупция куркынычына бәйле булган, дәүләти гражданлык хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар, шулай ук иренең (хатыны) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълүматлар тапшыруны таләп итүче Татарстан Республикасы дәүләти гражданлык хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрының беренче урынбасары – 1 берәмлек.

2. Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары – 3 берәмлек.

3. Министр ярдәмчесе – 2 берәмлек.

4. Идарә начальнигы – 4 берәмлек.

5. Эшләр идарәчесе – 1 берәмлек.

6. Бүлек начальнигы – 21 берәмлек.

7. Финанс һәм дәүләт заказы бүлеге:

бүлек начальнигы урынбасары – 1 берәмлек;

әйдәп баручы белгеч – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 1 берәмлек.

8. Дәүләт милкен арендалау, сату һәм инвестиция проектлары бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 3 берәмлек.

1 разрядлы өлкән белгеч – 1 берәмлек.

9. Торак, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч –+ 1 берәмлек.

10. Дәүләт милкеннән файдалану бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 3 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек.

11. Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге:

бүлек начальнигы урынбасары – 1 берәмлек;

әйдәп баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 2 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 2 берәмлек.

12. Җирләрнең категорияләрен үзгәртү һәм җир кишәрлекләрен торак пунктлар чикләренә кертү бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек;

әйдәп баручы белгеч-эксперт – 1 берәмлек.

13. Җир мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары белән берлектә эшләүне оештыру бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 2 берәмлек.

14. Икътисад бүлеге:

бүлек начальнигы урынбасары – 1 берәмлек;

әйдәп баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек.

15. Стратегик планлаштыру һәм хосусыйлаштыру бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек.

16. Корпоратив идарә бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы белгеч – 1 берәмлек.

17. Бәяләү бүлеге:

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 1 берәмлек.

18. ТР дәүләт мөлкәте реестры бүлеге:

бүлек начальнигы урынбасары – 1 берәмлек;

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч –1 берәмлек.

19. Архив секторы:

әйдәп баручы белгеч – 1 берәмлек.

20. Дәүләтнең мөлкәти мәнфәгатьләрен яклау бүлеге:

әйдәп баручы консультант – 2 берәмлек.

21. Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен хокукый яктан тәэмин итү бүлеге:

әйдәп  баручы киңәшче – 2 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек.

22. Кадастр мөнәсәбәтләре бүлеге:

әйдәп  баручы киңәшче – 1 берәмлек;

әйдәп баручы консультант – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 1 берәмлек.

23. Кадастр мөнәсәбәтләрен хокукый яктан тәэмин итү бүлеге:

әйдәп  баручы киңәшче – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 2 берәмлек;

1 разрядлы белгеч – 1 берәмлек.

24. Мәгълүматлаштыру бүлеге:

әйдәп  баручы белгеч – 1 берәмлек;

1 разрядлы өлкән белгеч – 1 берәмлек.

25. режим-яшеренлек хезмәте:

әйдәп баручы киңәшче – 1 берәмлек.